**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указлары үз көчен югалткан дип тану турында**

1. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урманнарда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тикшереп тору һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү юлы белән федераль дәүләт янгын күзәтчелеге дәүләт функцияләрен үтәүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 4 июлендәге ПУ-594 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан урманнарда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тикшереп тору һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү юлы белән федераль дәүләт янгын күзәтчелеге дәүләт функцияләрен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 19 декабрендәге ПУ-1242 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 15 гыйнварындагы ПУ-11 номерлы Указы.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 11 октябрь
№ ПУ-616